ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.02.2026 г. Казань № 6-3/соц-2026

«Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте өчен тариф билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 ноябрендәге 1208 номерлы «Татарстан Республикасында аутистик спектр бозылулары һәм башка психик тайпылышлары булган кешеләрне комплекслы озатып бару концепциясен раслау турында»гы, 2025 елның 5 июлендәге 486 номерлы «2025-2026 елларда «Аутистик спектр бозылулары һәм башка психик тайпылышлары булган инвалидларны социаль мәшгульлектә ярдәм итүне оештыру» пилот проектын гамәлгә ашыру турында»гы, 2025 елның 30 декабрендәге 1199 номерлы ««Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм 2026 елга «Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен күрсәтүгә җан башына финанслау нормативы турында»гы карарларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы Нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты Идарәсенең 2026 елның 11 февралендәге 3-ПР номерлы утырыш протоколына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә, «Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәтен тәкъдим итү өчен тарифны билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тариф үз көченә кергән карарның көненнән башлап 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.02.2026 № 6-3/соц-2026
карарына кушымта

«Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтүгә тариф

| № | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф |
|---|---|---|---|
| 1. | «Социаль мәшгульлекне оештыруда ярдәм күрсәтү» хезмәте күрсәтү | сум/сәгать | 78,19 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге